**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАТЮШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422624 д.Матюшино,
ул. Березовая, д.25
тел, факс: 267-01-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТЮШИНО БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422624 Матюшино авылы,
Каенлык урамы, 25 нчы йорт,
тел, факс: 267-01-44

2020елның 30 гыйнварендәге 1 номерлы

# КАРАР

**« Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр исәпкә алып), «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә, **карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлегендә, 1 нче, 2 нче кушымта нигезендә, 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 2019 елның 17 апрелендәге 6 номерлы Матюшино авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип таныrга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында -http:/laishevo.tatarstan.ru. адресы буенча бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

**Матюшино авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе** **Миннулина Н.И.**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль
районы Матюшино авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 30 гыйнварендәге
1 номерлы карарына
1 кушымта

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 1 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе<br>( сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3678,39 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 786,47 |
| 4. Кабер казу һәм күмү | 1660,00 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль
районы Матюшино авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 30 гыйнварендәге
1 номерлы карарына
2 кушымта

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 1 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе ( сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 178,39 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3500,00 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 786,47 |
| 5. Кабер казу һәм күмү | 1660,00 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |